СОВЕТ НИЖНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Советская, д.37А, с.Нижняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422164

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН УШМЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Совет ур., 37А нче йорт, Түбән Ушмы авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422164

тел.(факс): (85563) 2-34-46; e-mail: Noshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 1-5 «12» январь 2016 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы», «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Референдум үткәрү инициативасы турында»2015 елның 18 декабрендәге 55 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2015 елның 18 декабрендәге 2-4 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советының 2014 елның 02 апрелендәге 2-28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым салу чараларын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым салу турында нигезләмә нигезендә статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2016 елның 28 февраленә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге территориясендә

гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы  авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек  Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия  Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2016 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануын муниципаль контрольдә тотуны гамәлгә ашыру: Түбән Ошма торак пунктында юлларны ремонтлау
Партизан урамы 674 М.
Грейдер белән тигезләү – 134,8 мең сум.

«Әйе» «Юк»

3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек  Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы  авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Ганиевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы  авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Р.М.Ганиев
/